| Республика Татарстан<br>Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района | | Татарстан Республикасы<br>Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_09.09.2025_ Менделеевск ш. № 560

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 20 февралендәге 129 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында " 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1 Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау турында" 2025 елның 20 февралендәге 129 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Статья 2.22 КоАП РТ<br>Балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын ваклап сатуны чикләүне үтәмәү | - район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары,<br>- район Башкарма комитеты эшләре идарәчесе<br>- Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе. |

2. Әлеге карарны, Менделеевск муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru түбәндәге веб-адрес һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) буенча урнаштырып, халыкка җиткерергә:

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Ф.Искаков